Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Яңа Чүте авылында

2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2022 елның 17 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлеге Яңа Чуте авылы халык җыены нигезендә

Карар:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлеге Яңа Чуте авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урам утларын монтажлау, терәк, кабель, яктырткычлар сатып алу һәм аларны Тукай һәм Мәктәп урамнары арасында Яңа Чуте авылында урнаштыру;

- кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту.

3. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә), Баулы муниципаль районы сайтында бастырырга ( http://bavly.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ___________ З. С. Галләметдинов